**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423959, Республика Татарстан,
Ютазинский район, деревня Малые Уруссу,
улица Советская, дом 21А
тел. 85593 4-23-10, факс 85593 4-23-40

423959, Татарстан Республикасы,
Ютазы Районы, Кече Урыссу авылы,
Совет урамы, 21А йорты.
эл.адрес Tash.Utz@ tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29 гыйнвар 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ташкичү авыл җирлегенең Биектау торак пункты гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 20 ноябрендәге 12 санлы,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пункты гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 20 ноябрендәге 10 санлы,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пункты гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 21 ноябрендәге 14 санлы,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пункты гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 22 ноябрендәге 16 санлы карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Ташкичү авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы урынбасары А.А.Зарипова

Ташкичү авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2025 елның 29 гыйнварындагы
1 санлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган һәр граждан, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2025 елның 9 гыйнварыннан 2025 елның 20 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкара.

3. Түбәндәге очракларда нигезле сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт тормау,

б) авыру,

гражданнарга түләүне гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерү юлы белән, шулай ук кул куеп тапшыру, я почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртү) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша акча күчерү юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын акча керү турындагы касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

8. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгән очракта, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның “29 гыйнварындагы 1 санлы карарына 2 нче кушымта

Ташкичү авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адресы: ______________________________________________________________
_____________________________________________ нигезендә
____________________Сезгә _______________елның “___”_____________кадәр үзара салым түләү буенча узган җыен чараларын гамәлгә ашыру буенча түбәндәге реквизитлар буенча бер тапкыр түләнә торган сумма күчерергә кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү

Җитәкче _________________________________________________________
М.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Ташкичү авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ __________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адресы: ______________________________________________________________
«__» ________________ 20__ елны __________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.